**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ПР-180 от 25.09.2024 КАРАР

___________ № ______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм аңа үзгәрешләр белән, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон һәм аңа үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына һәм муниципаль мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә 2024 елның 31 декабренә кадәр локаль актларны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турындагы әлеге карарның 1 пунктында расланган нигезләмәгә туры китерергә.

3. Гамәлдән чыккан дип танырга:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында» 2014 елның 14 августындагы 512 номерлы карары;

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында» 2024 елның 23 сентябрендәге ПР-177номерлы карары.

4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар 2024 елның 25 сентябреннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов